ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 55-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 55-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 239-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлектә:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. **Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, төзекләндерү, җәмәгать тәртибен саклау, йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт һәм су объектларында кешеләрнең гомерен саклау өлкәсендә административ хокук бозулар**»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 3.18 статьяны өстәргә:

«3.18 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга карата өстәмә таләпләрне бозу**

1. Йорт хайваннарын күпфатирлы йортларның гомуми файдалану урыннарында һәм йорт яны территорияләрендә тоту, –

кисәтү ясауга яки ике меңнән дүрт мең сумга кадәр административ штраф салуга китерә.

2. Эт хуҗасының этне мәҗбүри теркәүне гамәлгә ашырмавы, –

кисәтү ясауга яки ике меңнән дүрт мең сумга кадәр административ штраф салуга китерә.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган гамәлләр бер ел эчендә тагын кабатлану, –

биш мең сум күләмендә административ штраф салуга китерә.»;

2) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 7.10 статьяны өстәргә:

«7.10 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы әлеге Кодексның 3.18 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

2. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең ветеринария куркынычсызлыгы һәм дәүләт күзәтчелегенең территориаль бүлекләре башлыклары карый.»;

3) 8.1 статьяда:

а) 1 өлештә «7.9» саннарыннан соң «, 7.10» саннарын өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлектәге $11^3$ өлешне өстәргә:

«$11^3$. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 3.18 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең ветеринария куркынычсызлыгы һәм дәүләт күзәтчелегенең территориаль бүлекләре консультантлары төзи.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Закон проекты хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә законнарны камилләштерү максатларында эшләнгән һәм хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын бозган өчен административ җаваплылык билгеләүне күздә тота.

«Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 8 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны урамда йөртүгә өстәмә таләпләр билгеләргә хокуклы.

Татарстан Республикасында тиешле таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә өстәмә таләпләр раслау турында» 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары белән билгеләнгән. Таләпләр арасында этләрне, республика территориясендә асрала торган этләрне мәҗбүри теркәү каралган, шулай ук йорт хайваннарын күпфатирлы йортларның гомуми файдалану урыннарында һәм аларның йорт яны территорияләрендә тоту тыелган.

Закон проекты тарафыннан тәкъдим ителә:

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3 бүлегенә (алга таба – Административ хокук бозулар турында ТР кодексы) Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга өстәмә таләпләрне бозган өчен административ җаваплылык билгели торган 3.18 статьяны өстәү;

әлеге статьяда каралган административ хокук бозулар турында эшләрне карауны һәм беркетмәләр төзүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләү.

Административ штраф рәвешендә административ җаваплылык йорт хайваннарын тотучы гражданнар өчен түбәндәге таләпләрне бозган очракта 2 мең сумнан 4 мең сумга кадәр билгеләнә:

1) йорт хайваннарын күпфатирлы йортларның гомуми файдалану урыннарында һәм аларның йорт яны территорияләрендә тоту;

2) эт хуҗасының этне мәҗбүри теркәүне гамәлгә ашырмавы.

Этне мәҗбүри теркәү турындагы таләпне кабат бозу биш мең сум күләмендә административ штраф салуга китерәчәк.

Закон проектын кабул итү хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гамәлдәге хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк, бу хайваннарны яклау максатларына ирешүгә, хайваннарга карата мөнәсәбәттә гражданнарның хокукларына ярдәм итәчәк.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәрешләр кертү яки кабул итү таләп ителми.

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы карарына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе тарафыннан закон проектында беркетелә торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында гамәлгә ашырылачак һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.